СОВЕТ
МАСАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЭСЭДЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

# КАРАР

2020 елның 15 июнь № 12

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Мәсәде авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә, Мәсәде авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Актаныш таңнары» газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Мәсәде авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Мәсәде авыл җирлеге Башлыгы: Ф.Р.Минһаҗетдинова

Совет Масадинского сельского поселения Актанышского муниципального района Республики Татарстан
ОГРН 1021605556023
ИНН 1604003454